**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 18 июнь | № 413

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.4.3 пунктчасын өстәргә:

«1.4.3. Чираттан тыш хезмәт күрсәтелүгә түбәндәгеләр хокуклы:

сугыш хәрәкәтләре инвалидлары;

Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

Бөек Ватан сугышында катнашучылар;

«Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнүчеләр;

Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә, хәрәкәттәге фронтларның операцион зоналары чикләрендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында һава оборонасы, җирле һава оборонасы объектларында, саклау корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар төзүдә эшләгән затлар;

Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында иректән мәхрүм ителгән транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзалары;

һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышы инвалидының, Бөек Ватан сугышында катнашучының, сугыш хәрәкәтләре инвалидының һәм сугыш хәрәкәтләре ветеранының каравында булган һәм карауччысын югалту очрагында Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә пенсия алган (аны алырга хокукы булган) эшкә яраксыз хатыны (эшкә яраксыз ире).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков